МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.02.2022 г.Казань № 140

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2022 елның 18 мартында 8972 номеры белән теркәлде

Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе рәвешен (тикшерү сораулары исемлеген) раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ санлы федераль законның 53 статьясындагы 1 өлеше нигезендә боерык бирәм:

1. Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган, кушымтада бирелгән тикшерү кәгазе рәвешен (тикшерү сораулары исемлеген) расларга.

2. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары К.А.Таҗетдиновага йөкләргә.

3. Әлеге боерык 2022 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль
яклау министрлыгының
28.02.2022 № 140
боерыгы белән расланды

**Үрнәк**

**Инвалидларны билгеләнгән квота чикләрендә эшкә кабул итүгә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда кулланыла торган тикшерү кәгазе рәвеше (тикшерү сораулары исемлеге)**

| |
|---|
| Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контрольлек (күзәтчелек) чараларының бердәм реестрын төзү һәм алып бару кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 28 апрелендәге 415 санлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 16 апрелендәге 604 санлы карарында каралган QR-код |

1. Дәүләт контроле (күзәтчелеге) төре: билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу өчен төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)

2. Контроль (күзәтчелек) органының атамасы:
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы.

3. Тикшерү кәгазе рәвешен раслау турында норматив хокукый акт белешмәләре: ________________________________________________

4. Контроль (күзәтчелек) чаралар төре: ___________________

5. Тикшерү битен тутыру көне: _________________________

6. Контроль (күзәтчелек) чарасы үткәрелә торган төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объекты: _______________________________________
__________________________________________________________________

7. Контрольдә тотылучы зат турында мәгълүмат:

гражданин яисә шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта):____________________________________

салым түләүченең тәңгәллек номеры һәм (яки) шәхси эшкуарның төп

дәүләт теркәү номеры:

___

гражданинның яки шәхси эшкуарның теркәлү адресы:

___

юридик затның исеме: ___

___

салым түләүченең тәңгәллек номеры һәм (яки) төп дәүләт теркәү номеры:___

юридик затның (аның филиалларының, вәкиллекләренең, аерымланган структур бүлекчәләрнең) адресы: ___

___

8. Тикшерү битен тутырып, контроль (күзәтчелек) чарасын үткәрү урыны: ___

___

9. Контроль (күзәтчелек) органының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзаланган контрольлек (күзәтчелек) чарасын үткәрү турында контрольлек (күзәтчелек) органы карары белешмәләре: ___

10. Контроль (күзәтчелек) чарасының исәпкә алу номеры: ___

11. Контрольлек төре турындагы нигезләмә, вазыйфаи регламент нигезендә контрольлек төре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, шул исәптән контрольлек (күзәтчелек) чараларын уздыру аның вазыйфаи бурычларына карый торган, контрольлек (күзәтчелек) чарасын уздырган һәм тикшерү кәгазен тутырган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы вазыйфаи затының вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары: ___

___

12. Аларга бирелгән җаваплар тикшерүдә тотылучы зат тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлүе яки үтәлмәве турында таныклый торган зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдырган сораулар исемлеге:

| Т/с | Зарури таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы сораулар | Зарури таләпләрне билгели торган норматив хокукый актларның, аларның бүленеш берәмлекләрен күрсәтеп, белешмәләре | Җаваплар | | | Искәрмәләр[1] |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Кулла-нып булмый | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Инвалидларны билгеләнгән квота нигезендә эшкә урнаштыру һәм инвалидларны күрсәтелгән эш урыннарына урнаштыру өчен эш урыннары булдыру яки бүлеп бирү | | | | | | |
| 1. | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен бүлеп бирелгән яки булдырылган эш урыннары инвалидларны билгеләнгән квоталар санына, махсус эш урыннарының иң аз күләмдәге санына туры киләме? | «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ санлы федераль законның (алга таба – 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ санлы федераль закон_ 24 статьясының икенче өлешендәге 1 пункты;<br><br>«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы) 6 статьясының 2 өлешендәге 1 пункты;<br><br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 санлы карары | | | | |

[1] «Искәрмә» графасы «җаваплар» графасында «кулланып булмый» дигән җавап күрсәтелгән очракта мәҗбүри тутырылырга тиеш.

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба – Нигезләмә) 3.1 пункты | | | | |
| 2. | Эшкә урнаштырылган инвалидлар саны инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квотага туры киләме? | «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 санлы Россия Федерациясе Законының $13^2$ статьясының 5 пункты;<br><br>2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьяның 11 өлеше | | | | |
| Булдырылган яисә бүлеп бирелгән эш урыннары турында мәгълүматны үз эченә алган локаль норматив актларны кабул итү | | | | | | |
| 3. | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары турындагы мәгълүматларны үз эченә алган локаль норматив акт кабул ителгәнме? | 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ санлы федераль законның 24 статьясының икенче өлешендәге 1 пункты;<br>2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясының 2 өлешендәге $1^1$ пункты<br>Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы икенче кызыл юлы | | | | |
| Татарстан Республикасының мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләренә мәгълүмат тапшыру | | | | | | |
| 4. | Инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бүлеп бирелгән эш урыннары турындагы мәгълүмат, әлеге эш урыннары турында белешмәләрне үз эченә алган локаль норматив актлар, инвалидларны түбәндәге ысулларның берсен сайлау юлы белән эшкә | «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 санлы Россия Федерациясе Законының 25 статьясының 3 пунктындагы өченче кызыл юлы;<br>Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкны эш белән тәэмин итү максатларында оператив күзәтү | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | алу өчен квотаны үтәү турындагы мәгълүматны да кертеп, Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәтенең дәүләт учреждениесенә ай саен тапшырылганмы:<br><br>а) мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформада белешмәләр һәм мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып;<br><br>б) турыдан-туры Татарстан Республикасы мәшгульлек хезмәтенең дәүләт учреждениесенә, яисә кушымталар исемлеге белән почта юлламасы рәвешендә, яисә гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен файдаланып, электрон документлар рәвешендә? | уздыру турында» 2022 елның 26 гыйнварындагы 24 санлы боерыгына 5 нче кушымта;<br><br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясының 3 пунктында каралган белешмәләрне һәм мәгълүматларны эш бирүчеләр тарафыннан тапшыру кагыйдәләре турында» 2021 елның 30 декабрендәге 2576 саенлы карары белән расланган «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы 3 пунктында каралган белешмәләрне һәм мәгълүматларны эш бирүчеләр тарафыннан тапшыру кагыйдәләренең 3 пункты | | | | |

«_____» ___________ 20___ ел.
(тикшерү битен тутыру көне күрсәтелә)

_____________________________ _______________________________________________________________ _______________

(тикшерү кәгазе тутырган затның вазыйфасы) (тикшерү кәгазе тутырган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)) (имза)